**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 31 октябрендәге 3777 номерлы карары**

**«Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс» архитектура проектларының Казан ачык конкурсын уздыру турында**

Казан шәһәренең архитектура һәм тышкы төзекләндерү өлкәсендәге казанышларын популярлаштыру максатыннан карар бирәм:

1. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә (А.П.Горбунов) Казанда архитектура проектлары буенча «Казан шәһәрендәге иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарларына смотр-конкурс» ачык конкурсын оештырырга.

2. Казанда архитектура проектлары буенча «Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарларына смотр-конкурс» ачык конкурсын уздыру турында нигезләмәне әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

3. Казанда архитектура проектлары буенча «Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарларына смотр-конкурс» ачык конкурсының жюри составын әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы А.Н.Лобовка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 21 октябрендәге
3777 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**«Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс» архитектура проектларының Казан ачык конкурсын уздыру турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казанда архитектура проектлары буенча «Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарларына смотр-конкурс» ачык конкурсын уздыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Казанда архитектура проектлары буенча «Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарларына смотр-конкурс» ачык конкурсын (алга таба – смотр-конкурс) уздыру тәртибен, смотр-конкурста катнашучыларга һәм тапшырылган эшләргә таләпләрне, аларны тәкъдим итү тәртибен, смотр-конкурсны уздыру вакытын регламентлаштыра.

Смотр-конкурсны уздыруның төп максаты – Казан шәһәренең архитектура, шәһәр төзелеше һәм тышкы төзекләндерү өлкәсендәге казанышларын, үзенчәлеклелеген һәм милли колоритын популярлаштыру.

Смотр-конкурсның төп бурычлары: биналарның һәм корылмаларның проект карарлары сыйфатын арттыру, шәһәр төзелеше белән бәйле карарларның дәрәҗәсен күтәрү, объектны комплекслы төзекләндерү буенча инновацион алымнарны гамәлгә кертү, архитекторларның һәм дизайнерларның һөнәри осталыгын камилләштерү.

1.2. Смотр-конкурсны оештыручы – «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе.

Смотр-конкурсны уздыру турында мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырыла.

1.3. Смотр-конкурс объектлары – түбәндәге өч категориягә караган проектлар һәм төзелеш объектлары (алга таба – проектлар):

- 1 категория – гамәлгә ашырылган, 2025 елның 1 июненнән файдалануга тапшырылган проектлар;
- 2 категория – гамәлгә ашырылмаган, Казан шәһәре Башкарма

комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе тарафыннан 2025 елның 1 июненнән объектның архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен килештерү турында карар кабул ителгән проектлар;

- 3 категория – карап тикшерү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә тапшырылмаган, идея һәм концепция дәрәҗәсендәге проектлар.

1.4. 1 һәм 2 категорияләргә караган проектлар номинацияләрдә (Нигезләмәнең II бүлеге) карап тикшерелә.

Казан шәһәре территориясендә объектларны урнаштыруны күздә тотыкан, 3 категориягә караган проектлар ирекле темага башкарылырга мөмкин.

## II. Смотр-конкурсның номинацияләре

Смотр-конкурсның номинацияләре:

- «Территорияләрне үстерүнең иң яхшы концепциясе»;
- «Коммерция билгеләнешендәге иң яхшы күчемсез милек объекты»;
- «Иң яхшы торак комплексы»;
- «Иң яхшы социаль объект»;

«Социаль объектның иң яхшы дизайны»;

- «Территорияләрне иң яхшы төзекләндерү»;
- «Тотрыклы үсеш өлкәсендә иң яхшы проект»;
- «Иң яхшы реновация объекты»;
- «Иң яхшы инженерлык-техник объект»;
- «Объектны архитектура-сәнгать ягыннан иң яхшы яктырту»;
- «Иң яхшы арт-объект»;
- «Иң яхшы шәхси торак йорт»;
- «Шәһәр халкы тавыш биргән объект» (Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) онлайн-тавыш бирү).

## III. Смотр-конкурсны уздыру урыны һәм вакыты

Смотр-конкурс: Казан шәһәре, Достоевский урамы, 35/10 йорт адресы буенча, оештыручының эш режимы нигезендә түбәндәге графикта үткәрелә:

- 2025 елның 1 ноябреннән - 2025 елның 10 ноябренә кадәр – катнашучыларның проектларын тапшыру;

- 2025 елның 14 ноябреннән 2025 елның 120 ноябренә кадәр – Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) ачык

онлайн-тавыш бирү;

- 2025 елның 21 ноябреннән 2025 елның 25 ноябренә кадәр – жюри утырышы, җиңүчеләрне һәм призерларны билгеләү;

- 2025 елның 4 декабреннән 2025 елның 7 декабренә кадәр – смотр-конкурсның җиңүчеләрен һәм призерларын игълан итү һәм бүләкләү.

Бүләкләүне уздыру урыны һәм вакыты турында мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) 2025 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

## IV. Смотр-конкурсны уздыру шартлары

4.1. Смотр-конкурста проект авторлары һәм (яки) аның хокук ияләре булып торучы, смотр-конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмә шартларына туры китереп гариза һәм проект тапшырган физик затлар – 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданнары шәхсән, шулай ук иҗади коллектив составында, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы затлар (үзмәшгульләр) (алга таба – катнашучылар) катнаша ала.

4.2. Һәр катнашучы берничә номинациядә һәм категориядә катнашу өчен гариза бирергә хокуклы.

4.3. Смотр-конкурста катнашу бушлай.

4.4. Конкурска тәкъдим ителгән проектлар түбәндәге сылтама буенча электрон рәвештә теркәлә: https://forms.yandex.ru/u/68d65f4190fa7b3348098159/.

4.5. Смотр-конкурста катнашу өчен түбәндәгеләрне үтәү мәҗбүри:

4.5.1. смотр-конкурска тәкъдим ителгән объектларны проектлаштыру муниципаль милектә булмаган җир кишәрлекләрендә яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылган очракта, җир кишәрлекләре милекчеләренең яисә аларның законлы хокук ияләренең язма ризалыгын тапшыру;

4.5.2. әлеге Нигезләмәнең 4.4 пунктында күрсәтелгән сылтама буенча әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта нигезендә гарантия хатын, шулай ук әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү.

4.6. Гаризаны тутыруга карата таләпләр:

4.6.1. объектның адресын, атамасын, проектларны гамәлгә ашыру аен һәм елын (1 категория өчен), шулай ук авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен/авторлык коллективы (барлык катнашучыларның да фамилиясен,

исемен, атасының исемен күрсәтеп) исемен күрсәтергә кирәк;

4.6.2. проект экспозициясен әлеге Нигезләмәнең V бүлеге белән регламентлаштырылган составта PDF форматындагы бердәм файл (20 MB дан артык түгел) рәвешендә беркетергә кирәк.

4.7. Смотр-конкурста катнашуга түбәндәгеләр кертелми:

- проектлары әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән критерийларга, әлеге Нигезләмәнең V бүлеге белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән, фотосурәтсез яки объектның урнашу урынын күрсәтмичә тапшырылган яисә объектның урнашу урыны анық фотосурәтенә туры килмәгән катнашучылар;

- гаризаны тутыруга карата әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән таләпләрне бозып, гариза тапшырган катнашучылар;

- смотр-конкурсны оештыручыга әлеге Нигезләмәнең 4.5 пунктында күрсәтелгән ризалыкларны тапшырмаган катнашучылар;

- «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләре.

## V. Проектларга карата таләпләр

5.1. Смотр-конкурска тәкъдим ителгән проектларны бәяләү критерийлары түбәндәгеләр:

- проект карарларының оригинальлеге һәм актуальлеге. Тәкъдим ителгән карарлар эшкә инновацион якын килүне күрсәтергә һәм архитектурадагы заманча тенденцияләргә туры килергә тиеш;

- образның уникальлеге һәм локаль үзенчәлекләрнең чагылышы. Проектта Казан шәһәренең мәдәни һәм тарихи үзенчәлекләре исәпкә алынырга тиеш;

- төгәллек һәм тәэсирлелек. Архитектура объекты гади формаларга, тәэсирле композициягә ия булырга тиеш;

- стиль белән бәйле карарның объектка һәм әйләнә-тирә мохиткә туры килүе. Проект әйләнә-тирәдә төзелгән биналарның үзенчәлеген исәпкә алырга һәм шәһәр мохите белән гармонияле ярашырга тиеш;

- проектны гамәлгә ашыруга комплекслы якын килү. Проект архитектура белән бәйле, шул ук вакытта функциональ һәм социаль аспектларны да исәпкә алырга тиеш. Бу аның шәһәр мохитенә һәрьяклап интеграцияләнүен тәэмин итәчәк;

- функциональлек һәм файдалы булу. Проект файдалануда уңайлы

булуын күрсәтергә, кулланучылар ихтыяҗларына җавап бирергә һәм пространствоны нәтиҗәле файдаланырга тиеш.

Смотр-конкурска тәкъдим ителгән проектлар әлеге бүлекнең күрсәтелгән таләпләре нигезендә комплексла карап тикшерелә.

5.2. Һәр номинациягә проект экспозициясе.

5.2.1. «Территорияләрне үстерүнең иң яхшы концепциясе» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;
- ситуация планын;
- гамәлдәге ситуация схемасын/фотофиксацияне;
- аналитик схемалар (гамәлдәге ситуациядә);
- аналитик схемаларны (тәкъдим);
- генераль планны, техник-икътисади күрсәткечләрне;
- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/аксонометрия).

5.2.2. «Коммерция билгеләнешендәге иң яхшы күчемсез милек объекты» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;
- ситуация планын;
- кимендә ике фасадны;
- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/аксонометрия/фотофиксация);
- участокның генераль планын.

5.2.3. «Иң яхшы торак комплексы» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- ситуация планын;
- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/аксонометрия/фотофиксация);
- участокның генераль планын;
- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын үз эченә алырга тиеш.

5.2.4. «Иң яхшы социаль объект» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- ситуация планын;

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация);

- участокның генераль планын;

- катлар (кат) планын;

- реконструкция яки капиталь ремонт үткәрелгән очракта, бинаның башлангыч торышы фотосурәтләрен/сызымнарын.

5.2.5. «Иң яхшы социаль объект интерьеры дизайны» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- ситуация планын;

- фотографияләрне/ беренчел бинаның сызымнарныы (объектны реновацияләүгә кадәр) (әгәр дә реновацияләү үткәрелгән булса);

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр);

- участокның генераль планын.

5.2.6. «Территорияләрне иң яхшы төзекләндерү» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- ситуация планын;

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация);

- участокның генераль планын.

5.2.7. «Тотрыклы үсеш өлкәсендә иң яхшы проект» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- тиешле схемаларны һәм материалларны урнаштырып, тотрыклы үсеш принципларын файдалану турында текстлы һәм графикалы мәгълүмат;

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация).

5.2.8. «Иң яхшы реновация объекты» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- объект һәм (яки) территория турында тарихи белешмә, реновациягә

кадәр объектның тасвирламасын;

- бинаның башлангыч торышы фотосурәтләрен/сызымнарын (реновациягә кадәр);

- ситуация планын;

- кимендә ике фасадны;

- бинаның әйләнә-тирәдәге корылмалар белән ничек ярашуын күрсәтү өчен, алар белән бер линиягә урнаштырылган шартлы сурәтен;

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация);

- участокның генераль планын.

5.2.9. «Иң яхшы инженерлык-техник объект» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- ситуация планын;

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация);

- участокның генераль планын.

5.2.10. «Объектны архитектура-сәнгать ягыннан иң яхшы яктырту» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- объектның ситуация планын;

- проект идеясен;

- яктылык җиһазлары урнаштырылачак урын турындагы белешмәләр нигезендә яктырткычлар сайлау буенча DIALux программасында башкарылган техник исәп-хисапны;

- фотофиксацияне (1 категория өчен);

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация);

- яктылык җиһазларын җитештерүченең атамасын күрсәтеп, җиһазларның спецификациясен.

5.2.11. «Иң яхшы арт-объект» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 MB дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- ситуация планын;

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация).

5.2.12. «Иң яхшы шәхси торак йорт» проекты экспозициясе (PDF форматындагы бердәм файл рәвешендә [20 МВ дан артмаска тиеш]) төрле битләрдә түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- идеянең тасвирламасын/аңлатмасын;

- ситуация планын;

- күрсәтмә чараларны (кимендә биш кадр) (перспективалы сурәтләр/ аксонометрия/фотофиксация);

- участокның генераль планын.

5.3. Һәр гаризага, экспозицияне гамәлгә ашыру һәм социаль челтәрләрдә, массакүләм мәгълүмат чараларында файдалану өчен, күрсәтмә кадрлар җыелмасы теркәлергә тиеш. Күрсәтмә кадрлар jpeg форматында кабул ителә, анда су билгеләре һәм логотиплар булмаска тиеш, рөхсәт ителгән пиксельләр саны – 1920×1080 нокталар (пиксельләр).

## VI. Жюри эше тәртибе

6.1. Смотр-конкурста җиңүчеләр һәм бүләкләнүчеләр жюри утырышында билгеләнә.

6.2. Жюри утырышы смотр-конкурста катнашучылардан башка уздырыла. Утырышны аның рәисе алып бара.

6.3. 1, 2 һәм 3 категорияләр буенча смотр-конкурста катнашуга кертелгән проектлар жюри әгъзалары тарафыннан электрон рәвештә карап тикшерелә.

6.4. Жюри проектны әлеге Нигезләмәнең V бүлегендә күрсәтелгән критерийларны һәм таләпләрне исәпкә алып бәяли.

6.5. Жюри һәр номинациядә бер җиңүчене һәм ике бүләкләнүчене билгели:

6.5.1. 1 категориядә җиңгән проект авторына диплом һәм номинация исеме белән объект өчен истәлекле элмә такта тапшырыла. 2 һәм 3 категорияләрдә җиңгән проектлар авторлары номинация исеме һәм яуланган урын күрсәтелгән дипломнар белән бүләкләнә;

6.5.2. икенче һәм өченче урыннарны яулган проектлар бүләкләнүчеләр булып таныла. Смотр-конкурсның бүләкләнүчеләренә яуланган урын һәм номинация исеме күрсәтелгән дипломнар тапшырыла.

6.6. Жюри утырышы турыдан-туры һәм читтән торып катнашу юлы белән үткәрелә.

6.7. Жюри утырышы, анда жюри әгъзаларының өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы булып санала.

Жюри әгъзасының смотр-конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгеләгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яисә читләтеп шәхси кызыксынуы килеп чыккан очракта, әлеге жюри әгъзасы бу хакта жюри утырышы башланганчы әйтергә тиеш. Мондый очракта жюри әгъзасы тиешле номинациядә җиңүчене һәм призерларны сайлауга карата жюри утырышында катнаша алмый.

6.8. Карар жюри эшендә катнашучы жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

6.9. Жюри утырышы көненнән 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча, утырыш нәтиҗәләре буенча беркетмә рәсмиләштерелә, ул жюри әгъзалары тарафыннан имзалана һәм жюри рәисе тарафыннан раслана.

6.10. Жюри рәисе һәм жюри рәистәше смотр-конкурста җиңүчеләрнең, бүләкләнүчеләрнең һәм катнашучыларның дипломнарын имзалый һәм бүләкләү чарасын үткәрә.

6.11. Жюри әгъзалары язма рәвештә аерым фикер белдерергә хокуклы, ул беркетмәгә кушымта итеп теркәлә.

## VII. Смотр-конкурска нәтиҗәләр ясау тәртибе

7.1. Смотр-конкурс нәтиҗәләре, смотр-конкурска йомгак ясалганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырыла. Смотр-конкурсны оештыручы смотр-конкурста җиңүчеләргә һәм бүләкләнүчеләргә мәгълүматны смотр-конкурсны оештыручыга бирелгән гаризада күрсәтелгән элемтә мәгълүматлары буенча хәбәр итә.

7.2. Смотр-конкурста җиңүчеләрнең һәм бүләкләнүчеләрнең проектлары Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырылырга тиеш.

## VIII. Смотр-конкурста катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары

8.1. Катнашучы түбәндәге хокукка ия:

8.1.1. әлеге Нигезләмә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) танышырга;

8.1.2. смотр-конкурста әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә

катнашырга;

8.1.3. смотр-конкурсны оештыручыдан смотр-конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе турында кирәкле мәгълүмат алырга.

8.2. Катнашучы әлеге Нигезләмә шартларын үтәргә йөкләмә ала.

8.3. Смотр-конкурста катнашу анда катнашучыларның әлеге Нигезләмә белән танышуын һәм тулысынча килешүен раслый.

8.4. Катнашучы конкурс проектының эчтәлеге, смотр-конкурсны оештыручыга бирелгән мәгълүматның төгәл һәм дөрес булуы өчен тулысынча җаваплы.

8.5. Смотр-конкурста катнашуга гариза биреп, катнашучы смотр-конкурсны оештыручыга конкурс проекты составында тапшырылган мәгълүматтан аналитик, мәгълүмати һәм гавами максатларда файдалануны рөхсәт итә.

## IX. Смотр-конкурсны оештыручының хокуклары һәм бурычлары

Смотр-конкурсны оештыручы:

- әлеге Нигезләмәгә туры килү-килмәү предметына смотр-конкурста катнашу өчен юлланган гаризаларны һәм башка мәгълүматны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә;
- катнашучылардан әлеге Нигезләмәнең үтәлүен таләп итә;
- гаризаларын тулысынча тутырмаган яки укый алмаслык итеп тутырган, гаризаларын күрсәтелгән вакыттан соңрак юллаган яисә смотр-конкурсны оештыручыга документларны (смотр-конкурска тапшырылган объектларны проектлау муниципаль милектәге булмаган җир кишәрлекләрендә яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылган очракта җир кишәрлекләре милекчеләренең яисә законлы хокук ияләренең язма ризалыгы, әлеге нигезләмәгә 1 номерлы кушымта нигезендә гарантия хаты, әлеге нигезләмәгә 2 номерлы кушымта нигезендә шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык) тапшырмаган (тулы күләмдә тапшырмаган) катнашучыларның гаризаларын карап тикшерми ;
- проектлары әлеге Нигезләмәнең V бүлеге таләпләренә туры килмәгән катнашучыларны смотр-конкурска кертми;
- смотр-конкурсны әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда уздырырга тиеш;
- жюри утырышы беркетмәләрен рәсмиләштерә.

---

«Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс» архитектура проектларының Казан ачык конкурсын уздыру турында Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта (форма)

«Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе директорына

**Гарантия хаты**

Мин,

_______________________________________________________________,
(катнашучы Ф.И.А)

Казанда архитектура проектлары буенча «Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарларына смотр-конкурс» ачык конкурсында катнашучы буларак, әлеге хат белән, смотр-конкурсны оештыручыга хокукларны тапшырып, проекттан түләүсез файдаланырга рөхсәт бирәм. Шул исәптән:

а) халыкка игълан итүгә, ягъни эшләрне нинди дә булса формада яки ысул белән билгеле булмаган затларга хәбәр итүгә хокукны;

б) таратуга хокукны;

в) проектны халык алдында күрсәтүгә хокукны;

г) халык игътибарына җиткерүгә хокукны;

д) презентация планшетыннан файдаланганда, аңа иллюстрацияләр, кереш сүз, комментарийлар яки нинди дә булса аңлатмалар белән үзгәрешләр, кыскартулар һәм өстәмәләр кертү хокукын.

/______________/_______________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

20________елның «_______»______________________

«Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс» архитектура проектларының Казан ачык конкурсын уздыру турында Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта (форма)

«Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе директорына

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин,
________________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

________________________________________________________________________,

____________________________________________________адресы буенча теркәлгән

________________________________________________________________________,

паспорт: сериясе ________ номеры ____________________«____» ____________________ бирелгән
(бирелү вакыты)

________________________________________________________________________
(документны биргән органның атамасы)

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9, 10 статьялары нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә 2025 елда «Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс» архитектура проектларының Казан ачык конкурсында катнашу һәм аңа нәтиҗәләр ясау, шул исәптән мәгълүмати ресурслардан файдаланып (www.kzn.ru), максатыннан минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә (тапшыруга, бирүгә, таратуга) ризалык бирәм.

Эшкәртелә торган шәхси мәгълүматлар исемлеге: фамилиясе, исеме,

атасының исеме (булган очракта), паспорт мәгълүматлары, белеме, вазифасы һәм эш урыны, элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы.

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив актлары нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә: җыюга, яздыруга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, төгәлләштерүгә (яңартуга, үзгәртүгә), алуга, куллануга, тапшыруга (таратуга, бирүгә, файдалануга мөмкинлек бирүгә), шәхси үзенчәлекләрне юк итүгә, тыюга, бетерүгә, юкка чыгаруга ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр исемлеге.

Конкурсны оештыручылар, шәхси мәгълүматлар субъектларының шәхси мәгълүматларын эшкәртү өчен автоматлаштырылган чаралар кулланып та, шулай ук автоматлаштырылган чаралар кулланмыйча да, шәхси мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыра.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык гамәлдә булу вакыты: әлеге ризалык аны имзалаган көннән алып шәхси мәгълүматлар субъекты аны язма рәвештә кире кайтарган көнгә кадәр гамәлдә була.

_____________________________________________ ______________________________

(Шәхси мәгълүматлар субъектының Ф.И.А.) (имза)

20________елның «_______»______________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 31 октябрендәге
3777 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**«Казан шәһәрендә иң яхшы архитектура һәм шәһәр төзелеше карарына смотр-конкурс» архитектура проектларының Казан ачык конкурсының жюри составы**

| | |
|---|---|
| Метшин Илсур Рәис улы | жюри рәисе, Казан шәһәре мэры (килешү буенча) |
| Төхфәтуллина Илсөяр Мисхәт кызы | жюри рәистәше, Казан шәһәренең баш архитекторы |

Жюри әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Шайнуров Альберт Маганави улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты рәисе |
| Белицкая Жанна Владимировна | Казан шәһәренең баш рәссамы, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары – шәһәр дизайны бүлеге башлыгы |
| Прокофьева Татьяна Георгиевна | «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе директорының беренче урынбасары – баш шәһәр төзүче |
| Мелкумова Нонна Георгиевна | Казан шәһәренең баш архитекторы урынбасары |
| Лешева Елена Сергеевна | Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең мәдәни мирас объектларын саклау бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Юлдашбаева Гүзәл Ради кызы | «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең концептуаль эшләнмәләр бүлеге башлыгы |
| Фәрхуллин Рүзәл Рәис улы | «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең җәмәгатьчелек киңлекләрен үстерү бүлеге башлыгы |
| Маршалова Валерия Анатольевна | «KOMANDA» стратегик менеджмент агентлыгы директоры (килешү буенча) |

_______________